ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11 декабрь, 2018 ел № 28/9

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 маддәләре нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 08 декабрендәге 6/5 санлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 04 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 09 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 05 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/10, 2017 елның 22 февралендәге 15/10, 2017 елның 10 августындагы 18/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/16, 2018 елның 27 апрелендәге № 24/8 санлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) **9 маддәнең 1 өлеше 26 пунктын** түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга «, планлаштырылучы шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объекты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир участогында шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты обьектын урнаштыру мөмкинлеге хакында хәбәр, планлаштырылучы шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объекты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яйсә)

җир участогында шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты обьектын урнаштыру мөмкин булмау хакында хәбәр, шәһәр округлары территорияләрендәге җир участокларында төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объекты реконструкциясе яйсә төзелеше шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килү яйсә туры килмәве хакында хәбәр, Россия Федерациясенең гражданлык законнарына туры китереп рөхсәтсез төзелешне җимерү хакында карар, рөхсәтсез төзелешне җимерү яйсә аны куелган таләпләргә туры китереп үзгәртү, максатчан билгеләнештә кулланылмаучы яйсә Россия Федерациясе законнарын бозып кулланылучы җир участогын алу хакында карарны җибәрү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда, рөхсәтсез төзелешне җимерү яки аны куелган таләпләргә туры китереп үзгәртү;»;

2) **9.1** маддәсенең **1 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 18 нче пунктны өстәргә:**

«18) Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендәге «кулланучылар хокукын яклау турында» 2300-1 санлы законында каралган тәртиптә, кулланучылар хокукын яклау буенча чаралар үткәрү.»;

3) **19 маддәнең 2 өлешендә беренче һәм икенче абзацта** «муниципаль берәмлек Башлыгы» сүзләреннән соң «яйсә Башкарма комитет Җитәкчесе» сүзләрен өстәргә;

4) **28 маддәдә:**

– **1 өлештәге 7 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) муниципаль предприятиеләрне төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү турында, шулай ук федераль законнарда каралган очраклардан тыш, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәтләренә тарифларны билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибен билгеләү;»;

– **2 өлештәге 58 пунктны** гамәлдән чыккан дип танырга;

5) **31 маддәнең 9 өлешендәге 2 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Шәхсән үзе яйсә ышанычлылылар аша эшмәкәрлек белән шөгыльләнү, коммерцияле оешма белән идарә итү яки аның идарәсендә катнашу (Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партияләрдә, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан башка), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә, оешманың коллегиаль

органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан; муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә кую һәм идарә итү вәкаләтләрен башкару тәртибен билгеләүче муниципаль-хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органында яйсә ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез башкарудан, федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш;»;

6) **41 маддәдә:**

– **2 өлеш 7 пунктта** «ябык» сүзен «гавами булмаган» сүзләренә алыштырырга;

– **4 өлештә:**

түбәндәге эчтәлектәге **13.8 һәм 13.9** пунктларын өстәргә:

«13.8) шәһәр округлары территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә шәхси торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә белдерү кәгазен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 маддәсе 7 өлеше, 2 пунктында, 8 өлеше 3 пунктында, 55 маддәсе 19 өлеше 5 пунктында каралган тәртиптә җибәрү;

13.9) рөхсәтсез төзелгән бинаны сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында (гражданлык законнарында каралган очракларда)карар кабул итү, рөхсәтсез төзелгән бинаны сүтү яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда).»;

**14 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) шәһәр территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыруга кагылышлы өлештә шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларын алып бару һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларындагы белешмәләрне, документларны һәм материалларны бирү;»;

– **9 өлештә**:

**1 пунктны** көчен югалткан дип танырга;

**2 пунктта** «Шәһәр Советы Карарлары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

Түбәндәге эчтәлектәге **9.3.1 һәм 9.3.2** пунктларын өстәргә:

«9.3.1) муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чараларын координацияләү һәм аларның үткәрелүен контрольдә тоту;

9.3.2) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә 2009 елның 23 ноябрендәге «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 261-ФЗ санлы Федераль закон, башка федераль законнар тарафыннан җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;»;

**9.8 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.8) җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен хәл итүче оешмаларның инвестицион программаларын килештерү, электр энергетикасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә килештерелә торган программалардан тыш;»;

Түбәндәге эчтәлектәге **9.8.1 пунктын өстәргә:**

«9.8.1) җылылык белән тәэмин итү схемаларын эшләү, раслау һәм актуальләштерү тәртибенә таләпләр нигезендә шәһәрне җылылык белән тәэмин итү схемасы проектын яисә җылылык белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасы проектын эшләү һәм аны раслау өчен җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына җибәрү;»;

**9.16 пунктны** гамәлдән чыккан дип танырга;

түбәндәге эчтәлектәге **9.18.1** пунктын өстәргә :

«9.18.1) агып җыела торган су составының нормативларын билгеләү;»;

– **11 өлештә:**

**1, 2, 6 пунктларны** гамәлдән чыккан дип танырга;

**8 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) сәүдә, көнкүреш хезмәте һәм кулланучыга башка төр хезмәтләр күрсәтүче муниципаль оешмаларның эш режимын билгеләү;»;

**11 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) бакчачылык алып баруга ярдәм күрсәтү;»;

**12 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендәге «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 2300-1 санлы Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру;»;

– **13** өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Мәдәният өлкәсендә:

1) халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, шәһәр китапханәләренең фондларын туплауны һәм саклауны тәэмин итү;

2) шәһәр халкына ял итүне оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

3) җирле традицион халык сәнгатен, иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәрдә халык һөнәрчелеген саклау, яңадан торгызу һәм үстерүдә катнашу;

4) муниципаль милектә булган мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану һәм популярлаштыру;

5) җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы;

6) җирле (муниципаль) әһәмияттәге тарихи-мәдәни тыюлыкны оештыру тәртибен билгеләү;

7) милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга, шәһәр территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен

һәм мәдәниятен үстерүгә, милли азчылыкларның хокукларын тормышка ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара (этникара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

8) муниципаль милектә булган мәдәни мирас объектларында инвалидлар хәрәкәте өчен шартлар тудыру;

9) 2002 елның 25 июнендәге «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 73-ФЗ санлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда каралган башка вәкаләтләр;»;

– **18.2 өлешне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18.2. Башкарма комитет муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Муниципаль контроль төрләре исемлеге Башкарма комитет тарафыннан алып барыла.

Исемлеккә түбәндәге белешмәләр кертелә: муниципаль контроль төре исеме; муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләр бирелгән Башкарма комитет органнарының исеме, аларның урнашу урыны, телефоны; муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча Башкарма комитет органы вәкаләтләрен билгели торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актының, муниципаль норматив хокукый актның исеме һәм реквизитлары; муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында муниципаль норматив хокукый актның исеме һәм реквизитлары.

Муниципаль контроль өлкәсендә Башкарма комитет вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) шәһәр территориясендә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү. Административ регламентларны эшләү һәм кабул итү Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;

3) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контроль нәтиҗәлелеге мониторингын оештыру һәм үткәрү, аны үткәрү күрсәткечләре һәм методикасы законнар нигезендә раслана

4) федераль законнарда, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру буенча функцияләр Башкарма комитет органнарына мондый органнарның статусын билгели торган хокукый актлар нигезендә йөкләнергә мөмкин.»

7) **42 маддәнең 2 өлешен** түбәндәге эчтәлектәге **8.1 пункты** белән тулыландырырга:

«8.1) җәмәгать тыңлаулары, җәмәгать фикер алышулары үткәрү инициативасы белән чыга;»;

8) **55 маддәне** яңа редакциядә бәян итәргә:

«55 маддә. Муниципаль хокукый актларны, җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү)

1. Муниципаль хокукый актны, җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) дигәндә аның тулы текстын «рәсми бастыру» билгесе белән Шәһәр Советы карары нигезендә рәсми бастыру чыганагы дип билгеләнгән массакүләм мәгълүматның басма чарасында беренче бастыру һәм муниципаль хокукый актның, җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең тулы текстын «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru) беренче урнаштыру (бастыру) аңлашыла.

2. Мәҗбүри рәсми басылып чыгарга (халыкка игълан ителергә) тиешле җирле үзидарә органының һәм җирле үзидарә органы вазыйфаи затының муниципаль хокукый акты яйсә җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешү әлеге актны кабул иткән (килешүне төзегән) орган яки вазифаи зат тарафыннан матбугат басмасына юнәлтелә.

Муниципаль хокукый актны яки җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә бастыру (халыкка игълан итү) аңа кул куелган көннән алып җиде көннән дә соңга калмыйча башкарыла.

3. Муниципаль хокукый актның яки җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең төп нөсхәсе белән чагыштырганда рәсми рәвештә матбугатта басылып чыккан муниципаль хокукый актта яки килешүдә хаталар, төгәлсезлекләр киткән очракта, хаталар, төгәлсезлекләр табылганнан соң, шул ук басмага муниципаль хокукый актны кабул иткән җирле үзидарә органының яисә җирле үзидарә органының вазыйфаи заты тарафыннан яки килешүгә кул куйган җирле үзидарә органынын төгәлсезлекләрне төзәтү турында рәсми хәбәре бирелергә һәм муниципаль хокукый актның яйсә җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең тиешле нигезләмәләрнең төп нөсхәсе басылырга тиеш.

4. Муниципаль сайлаулар, җирле референдумнар, Шәһәр Советы депутатларын чакыртып алу буенча тавыш бирү, чикләрне үзгәртү, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре, шәһәр Хакимен, муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарын сайлау, Башкарма комитет Җитәкчесен, Контроль-хисап палатасы Рәисен билгеләү турында норматив булмаган хокукый актлар һәм законнар нигезендә башка актлар мәҗбүри һәм рәсми рәвештә матбугатта басылып чыгарга (игълан ителергә) тиеш.

5. Муниципаль хокукый актлар һәм җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр “Интернет” челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырылырга, халыкка телевидение һәм радио аша хәбәр ителергә, хакимиятнең дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, вазыйфаи затларга, шәһәр оешмаларына җибәрелергә мөмкин.

Муниципаль хокукый актлар һәм җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр аерым басма булып чыгарылырга мөмкин.»;

6) **59 маддәнең 3 өлешендә** «ябык» сүзен «гавами булмаган» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге Карар матбугатта рәсми басылган көннән үз көченә керә, нигезләмәләр өчен үз көченә керү гамәлдәге законнар белән башка вакытта каралган.

3. Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевкә әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә юнәлтергә.

4. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе, законлылык һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2018 елның 14 декабрендә теркәлде. Дәүләт теркәве номеры RU 163020002018002.